КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 14 гыйнвар г.Казань № 9

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итүнең өстәмә чаралары турында» 2007 ел, 18 декабрь, 732 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 16 май, 326 нчы; 2008 ел, 29 август, 619 нчы; 2011 ел, 20 декабрь, 1021 нче; 2013 ел, 11 июнь, 398 нче; 2020 ел, 27 октябрь, 964 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сертификат формасын расларга»;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

3 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында» 2007 ел, 18 декабрь, 732 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 16 май, 326 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 29 август, 619 нчы; 2009 ел, 15 июнь, 394 нче; 2011 ел, 20 декабрь, 1021 нче; 2013 ел, 11 июнь, 398 нче; 2016 ел, 27 июнь, 443 нче; 2016 ел, 27 июль, 515 нче; 2016 ел, 5 декабрь, 891 нче; 2017 ел, 24 октябрь, 806 нчы; 2019 ел, 9 август, 660 нчы; 2020 ел, 24 февраль, 131 нче; 2020 ел, 6 март, 172 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның алтынчы – тугызынчы абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләрендә:

2 пунктта:

беренче абзацта «сатып алу өчен субсидия», «(алга таба – субсидия)» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ, биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары кысаларында бу Кагыйдәләрнең 4 нче пунктында күрсәтелгән гражданнарга торак урын алу хокукы бер тапкыр бирелә.»;

6 пунктта «субсидиянең» сүзен «бирелә торган торак урынның гомуми мәйданы» сүзләренә алмаштырырга, «һәм аның гамәлдә булу вакытының барлык чорында үзгәрешсез кала» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 пунктта «Субсидияләр күләмен исәпләп чыгару өчен» сүзләрен төшереп калдырырга;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Бирелә торган торак урынның гомуми мәйданы, күпбалалы гаилә яшәгән торак урынның гомуми мәйданын тотып калып (алар биләгән торак урын санитария нормаларына һәм яшәү кагыйдәләренә туры килгән очракта), бу Кагыйдәләрнең 7 пунктында билгеләнгән торак урынның гомуми мәйданы нормативыннан чыгып билгеләнә.

Күпбалалы гаилә һәм (яки) гаиләнең аерым әгъзалары тарафыннан аларның милек хокукында булган торак урын (торак урыннар) йә әлеге гражданнарның торак урынга уртак милек хокукындагы өлеше алынган очракта, бирелә торган торак урынның гомуми мәйданы күләме бу Кагыйдәләрнең 7 нче пунктында күрсәтелгән норматив буенча билгеләнгән торак урынның гомуми мәйданы һәм күпбалалы гаилә тарафыннан социаль наем шартнамәләре, социаль файдаланудагы торак фондның торак урыннары наем шартнамәләре буенча биләнә торган һәм (яки) күпбалалы гаиләнең һәм (яки) аерым гаилә әгъзаларының милек хокукында булган торак урыннарның (алар биләгән торак урыннар санитария нормаларына һәм яшәү кагыйдәләренә туры килгән очракта) һәм алынган торак урынның (торак урын милекчеләренең килешүендә билгеләнгән яки торак урынга уртак милек хокукындагы өлешләренә пропорциональ исәпләнгән, аерым гаилә әгъзасына туры килә торган торак урынга милек хокукындагы өлешнең) кушылган гомуми мәйданы арасындагы аерма буларак билгеләнә. Әлеге граждан-хокукый алыш-бирешләр күпбалалы гаиләгә сертификат биргәнгә кадәр булган биш ел өчен исәпкә алына.»;

9 пунктның «д» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлеше белән билгеләнгән органнар тарафыннан гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының торак урыннарга милек хокуклары булуы (булмавы) турында, шулай ук бу пункт белән карал-

ган документларны тапшырган көнгә кадәр кимендә биш ел эчендә алардан баш тарту буенча алыш-бирешләр башкару турында мәгълүматлар бирелә торган документлар (документлардан өземтәләр);»;

12 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

16 пунктның беренче һәм икенче абзацларында «гражданнарның җыелма исемлеген» сүзләрен «Татарстан Республикасында күпбалалы гаиләләрнең җыелма исемлеген» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлектәге $16^1$ пункт өстәргә:

«$16^1$. Җирле үзидарә органнары Министрлыкның соравы буенча планлаштырыла торган елга Татарстан Республикасында күпбалалы гаиләләрнең җыелма исемлеге расланган көннән 10 көн эчендә планлаштырыла торган елга Татарстан Республикасында күпбалалы гаиләләрнең җыелма исемлегенә кертелгән гражданнарның билгеләнгән тәртиптә расланган исәпкә алу эшләре күчермәләрен кертә, анда түбәндәге документлар бирелә:

әлеге Кагыйдәләрнең 9 пунктында күрсәтелгән документлар;

җирле үзидарә органының гражданны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә кую турындагы карары;

җирле үзидарә органының гражданны сертификатлар алу өчен гражданнар исемлекләренә кертү турындагы карары.

Исәпкә алу эшенең тулы булмаган документлар пакеты аны тапшырган көннән 10 көн эчендә эшләп бетерү өчен Министрлык тарафыннан җирле үзидарә органына кире кайтарыла.

Җирле үзидарә органнары биш көн эчендә Министрлык тарафыннан кире кайтарылган исәпкә алу эшләрен бу пункт белән билгеләнгән таләпләр нигезендә эшләп бетерүне оештыра һәм аларны Министрлыкка кабат җибәрә.»;

17 пунктның дүртенче абзацында «, үзләренә беркетелгән торак урыны булмаган ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар» сүзләрен төшереп калдырырга;

17 пунктның бишенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

18 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

19 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Министрлык планлаштырыла торган елның 1 апреленә кадәр исәпкә алу эшләренең тапшырылган күчермәләре нигезендә сертификатларны рәсмиләштерә һәм аларны гражданнарга тапшыру өчен җирле үзидарә органнарына җибәрә.»;

21 пунктның икенче һәм өченче абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

25 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

26 пунктта «бирелгән сертификатлар реестрларыннан җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырылган өземтәләр нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

29 пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

30 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

32 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32. Сертификатны алыштырган очракта, Министрлык яңа сертификатның югары уң почмагында түбәндәге эчтәлекле билге ясый: « ________ серияле, ________ номерлы сертификатка алмашка бирелә».»;

33 пунктта:

беренче абзацта «сатып алу» сүзләрен «алу» сүзенә, «махсуслаштырылган оешма счетына субсидия акчасын күчерү турында» сүзләрен «торак урын сайлау турында» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «махсуслаштырылган оешма счетына субсидия акчасын күчерү турында» сүзләрен «торак урын сайлау турында» сүзләренә алмаштырырга;

34 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«34. Махсуслаштырылган оешма һәм сертификат хуҗасы арасында килешү буенча сертификатта күрсәтелгән гомуми мәйдан күләменнән артып киткән гомуми мәйданлы торак урын, гомуми мәйдан аермасын түләп, үз һәм (яки) заем (кредит) акчасын файдаланып бирелергә мөмкин.»;

35 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«35. Күпбалалы гаиләгә бирелә торган торак урын (урыннар) сертификат хуҗасы гаиләсенең барлык әгъзаларының гомуми милкенә рәсмиләштерелә. Ике һәм аннан күбрәк торак урыннар биргәндә, әлеге торак урыннарга милек хокукы гаилә әгъзаларының килешенүләре буенча рәсмиләштерелә.»;

36 пунктта:

«аңа» сүзен төшереп калдырырга, «түләү» сүзе алдына «сертификатка» сүзен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Сертификат өчен түләү суммасы сертификатта күрсәтелгән гомуми мәйдан күләменнән һәм, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының сертификатны рәсмиләштерү көненә гамәлдә булган боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар кыйммәтеннән чыгып билгеләнә.»;

37 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«37. Министрлык сертификат хуҗасының торак урынны сайлап алу турындагы гаризасын һәм заявкасын алган көннән 10 көн эчендә махсуслаштырылган оешма счетына сертификат өчен түләүгә акча күчерә.»;

38 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«38. Муниципаль берәмлек территориясендә махсуслаштырылган оешма тарафыннан төзелеше финансланган торак урыннар булмаган очракта, бу Кагыйдәләрнең 4 нче пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән гражданнар, махсуслаштырылган оешма белән килештереп, башка муниципаль берәмлек территориясендә төзелеше махсуслаштырылган оешма тарафыннан финансланган торак йортлардагы торак урынны сайлап алу хокукын ала.»;

39 пункт үз көчен югалткан дип таныргa;

$40^1$ пунктта «сатып алуга субсидияне» сүзләрен «алу хокукын» сүзләренә алмаштырырга;

$40^2$ пунктта «субсидияләр» сүзен «торак урыннарның гомуми мәйданы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Кагыйдәләргә 5 нче кушымтада 5 графа исемендәге «бирелә торган субсидия күләме, сум» сүзләрен «бирелә торган торак урынның гомуми мәйданы күләме, кв.метр» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Кагыйдәләргә 6 нчы кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге Кагыйдәләргә 7 нче кушымта үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренә 6 нчы кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 20 гыйнвар, 14 нче карары редакциясендә)

Форма

___________________________________
(башкарма хакимият органы җитәкчесенә)
___________________________________
(почта адресы)
_______________ адресы буенча яшәүче
граждан(ка) _________________________,
(фамилиясе, исеме,
___________________________________
атасының исеме (соңгысы – булганда)

# Гариза

Миңа, ____________________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))
паспорт ________________________, ________ елның «_____» ____________нда (ндә) ______________
_________________________________________________________________ тарафыннан бирелгән,
___________________________________________________________ территориясендә торак белән
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге исеме)
тәэмин итү өчен сертификат бирүегезне үтенәм.

Гаилә составы: хатыны (ире) ___________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының (соңгысы – булганда), туган көне)
паспорты ____________________, ________ елның «_____» ____________нда (ндә) _________________
_________________________________________________________________ тарафыннан бирелгән,
___________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________ адресы буенча яши;
балалар: _____________________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), туган көне)
паспорты (туу турында таныклыгы) ________________________________________, ________ елның
«_____» ____________нда (ндә) ________________________________________ тарафыннан бирелгән,
____________________________________________________________________ адресы буенча яши;
__________________________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), туган көне)
паспорты (туу турында таныклыгы) ________________________________________, ________ елның
«_____» ____________нда (ндә) ________________________________________ тарафыннан бирелгән,
____________________________________________________________________ адресы буенча яши;
__________________________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), туган көне)
паспорты (туу турында таныклыгы) ________________________________________, ________ елның
«_____» ____________нда (ндә) ________________________________________ тарафыннан бирелгән,
____________________________________________________________________ адресы буенча яши;
__________________________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), туган көне)

паспорты (туу турында таныклыгы) ________________________________________, _______ елның «_____» ___________нда (ндә) ___________________________________ тарафыннан бирелгән, ____________________________________________________________________ адресы буенча яши;

__________________________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), туган көне)

паспорты (туу турында таныклыгы) ___________________________________, _______ елның «_____» ___________нда (ндә) ______________________________________ тарафыннан бирелгән, ____________________________________________________________________ адресы буенча яши.

Моннан тыш, минем белән башка гаилә әгъзалары да яши:

__________________________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), туган көне)

паспорты __________________________, _______ елның «_____» ______________нда (ндә) ________ ________________________________________________________________ тарафыннан бирелгән.

_______________________________________________________________________________ нигезендә
(норматив акт исеме)

__________________________________________________________________________________
(Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән

__________________________________________________________________ категориясенә карыйм,
торак урын алу хокукына ия гражданнар категориясе исеме)

торак шартларын яхшыртуга (торак урыннар алуга) мохтаҗ дип танылдым һәм _________ елның «__» _________ нан(нән) ________________________________________________________________
(исәпкә кую урыны)

_________________________________________________________________________ чиратта торам.

________________ номерлы исәпкә алу эше.

I. Хәзерге вакытта минем һәм минем гаилә әгъзаларымның Россия Федерациясе территориясендә даими яшәү өчен торак урыннары юк (бар).
(кирәк булмаганын сызарга)

Минем һәм (яки) минем гаилә әгъзаларым социаль наем шартнамәләре буенча яшәгән һәм (яки) милек хокукында минеке һәм (яки) минем гаилә әгъзаларымныкы булган торак урыннар булу турында мәгълүматлар:

| Т/с | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | Торак урыны булган затның сертификат алучы белән туганлык мөнәсәбәтләре | Торак урын урнашу урынының почта адресы | Торак урынның төре, гомуми мәйданы, кв.метр | Файдалану нигезләре (социаль наем шартнамәсе яки милек хокукы нигезендә), шартнамә датасы һәм реквизитлары, милек хокукы турында таныклык реквизитлары |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | |
| 2. | | | | | |
| 3. | | | | | |

II. Милек хокукында минеке һәм (яки) минем гаилә әгъзаларымныкы булган торак урыннан баш тартуга китергән граждан-хокукый алыш-бирешләр (бу торак урыннан дәүләт милке яки муниципаль милек файдасына баш тартудан тыш) башкардым (башкармадым).
(кирәк булмаганын сызарга)

Милек хокукында минеке һәм (яки) минем гаилә әгъзаларымныкы булган торак урыннан баш тартуга китергән граждан-хокукый алыш-бирешләр (бу торак урыннан дәүләт милке яки муниципаль милек файдасына баш тартудан тыш):

| Т/с | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | Торак урыннан баш тартуны башкарган затның сертификат алучы белән туганлык мөнәсәбәтләре | Торак урын урнашу урынының почта адресы | Торак урынның төре, гомуми мәйданы, кв.метр | Торак урыннан баш тартуга китергән граждан-хокукый алыш-бирешләр һәм әлеге алыш-бирешләр башкару фактын раслый торган документлар реквизитлары |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | |
| 2. | | | | | |
| 3. | | | | | |

Мин һәм минем гаилә әгъзалары әлеге мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын раслыйбыз. Федераль башкарма хакимият органнарында (Федераль салым хезмәтен, Федераль миграция хезмәтен, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтен кертеп) тапшырылган документларны тикшерүгә, шулай ук шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәбез.

Мин, ______________________________________________________________________________,
( фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) ,
үзем биргән мәгълүматларда һәм гаризага теркәгән документларда дөреслеккә туры килми торган һәм дәүләт торак сертификаты алу өчен нигез булган мәгълүматлар булуы ачыкланган очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартылу турында кисәтелдем.

Субсидия акчасыннан файдаланып, торак урын сатып алганнан соң торак шартларын яхшырту (торак урыннар алу) чиратыннан мине төшереп калдыруга риза.

Гаризага түбәндәге документларны терким:

1) ______________________________________________________________________________;
(документның исеме һәм номеры, кем һәм кайчан биргән)
2) ______________________________________________________________________________;
(документның исеме һәм номеры, кем һәм кайчан биргән)
3) ______________________________________________________________________________;
(документның исеме һәм номеры, кем һәм кайчан биргән)
4) ______________________________________________________________________________;
(документның исеме һәм номеры, кем һәм кайчан биргән)
5) ______________________________________________________________________________;
(документның исеме һәм номеры, кем һәм кайчан биргән)
6) ______________________________________________________________________________;
(документның исеме һәм номеры, кем һәм кайчан биргән)
7) ______________________________________________________________________________;
(документның исеме һәм номеры, кем һәм кайчан биргән)
8) ______________________________________________________________________________.
(документның исеме һәм номеры, кем һәм кайчан биргән)

Сертификатны алу һәм аннан файдалану шартлары белән таныштым һәм аларны үтәргә вәгъдә бирәм.

_____________________________________________ ______________________ ___________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) (имзасы) (датасы)

Гаиләнең балигъ булмаган әгъзалары гариза белән риза:

1) __________________________________________________ ______________________;
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) (имзасы)
2) __________________________________________________ ______________________;
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) (имзасы)
3) __________________________________________________ ______________________;
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) (имзасы)
4) __________________________________________________ ______________________;
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) (имзасы)
5) __________________________________________________ ______________________;
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) (имзасы)
6) __________________________________________________ ______________________;
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) (имзасы)
7) __________________________________________________ ______________________.
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) (имзасы)

____________________________________________________________________________
гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының имзасын раслый торган нотариаль язу)
____________________________________________________________________________

____________________________